ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК

ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.05.2022 г.Лениногорск № 14

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020ның 4 мартындагы 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга пассажирлар йөртүне оештыру һәм җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү буенча чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон (2022 елның 14 мартындагы редакциядә) нигезендә, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 ның 4 мартындагы 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга пассажирлар йөртүне оештыру һәм җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү буенча чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

каплауга субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 1.7 һәм 1.8 пунктлар белән тулыландырырга:

«1.7. Субсидия бирү нәтиҗәләре конкрет, үлчәнешле булырга һәм әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән мәгънәләре килешүдә билгеләнә торган тиешле проектлар нәтиҗәләренә ирешүгә планлаштырылучы нәтиҗәләргә туры килергә тиеш.

1.8. Субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр-бюджет акчаларын максатчан файдалану.»;

2.11 пунктының 2 абзацын «,әлеге Нигезләмәнең 2.14 пунктында каралган» сүзләре белән тулыландырырга;

2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14) Субсидияләр алучыларга һәм әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә күрсәтелгән затларга карата Лениногорск шәһәре Башкарма комитеты һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Контроль-хисап палатасы» МКУ тарафыннан субсидияләр бирүгә, алар тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешенә, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Финанс-бюджет палатасы» МКУ тикшерүләрен гамәлгә ашыру турында нигезләмәләр»;

4 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшереп тору (мониторинг) турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык.

4.1. Субсидия алучы тарафыннан аны бирү шартларын бозган очракта, субсидияне күчерү җитешсезлекләрне бетергәнчегә кадәр туктатыла.

4.2. Субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны үз эченә ала:

а) Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты, «Контроль-хисап палатасы» МКУ, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан субсидия алучыларга субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәү буенча мәҗбүри тикшерү уздыру;

б) субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылганда, җаваплылык чаралары кулланыла:

Лениногорск шәһәре Башкарма комитеты һәм (яисә) дәүләт финанс тикшерүе органы (Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Контроль-хисап палатасы» МКУ, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУ) таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр акчаларын кире кайтару, түбәндәге очракларда:

субсидия алучы тарафыннан субсидияләр биргәндә, шул исәптән тикшерүләр фактлары буенча да - тулы күләмдә субсидия алу шартларын бозу (субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактларын ачыклау);

әлеге Нигезләмәнең 1.7, 1.8 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәләр һәм күрсәткечләр күрсәткечләренә ирешмәү - тулы күләмдә;

субсидиядән файдалану турында хисапны тапшырмау, хисап тапшыру срокларын тулысынча бозу – тулы күләмдә;

субсидия акчаларыннан максатчан файдаланмауны ачыклау - субсидиянең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган күләмдә.

4.3. Хисап финанс елында кулланылмаган субсидия калдыгы, субсидия бирү турындагы килешүдә каралган очракларда, субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык Департаментының территориаль бүлегендә ачылган Башкарма комитетның шәхси счетына күчерү юлы белән киләсе елның 1 гыйнварына кадәр бюджетка кире кайтарылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Р. Сытдиков

Л.М. Галимова
5-44-72